ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Гаилә кодексының 110 һәм 114 статьяларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Гаилә кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 9 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 5, № 7; 2014, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 110 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“110 статья. **Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны ачыклау һәм исәпкә алу**

1. Оешмаларның (мәктәпкәчә мәгариф оешмаларының, гомуми белем бирү оешмаларының, медицина оешмаларының һәм башка оешмаларның) әлеге Кодексның 109 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән балалар турында белешмәләрдән хәбәрдар булган вазыйфаи затлары һәм бүтән гражданнар бу хакта балалар фактта булган урындагы опека һәм попечительлек органнарына хәбәр итәргә тиеш.

2. Опека һәм попечительлек органы мондый белешмәләр алган көннән алып өч эш көне дәвамында баланың яшәү шартларын тикшерүне уздырырга һәм, ата-анасының яисә туганнарының аны тәрбияләмәү факты билгеләнгәндә, баланы урнаштыру мәсьәләсе хәл ителгәнгә кадәр аның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауны тәэмин итәргә, шулай ук бу бала турында булган мәгълүматны ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар хакында республика белешмәләр банкында беренчел исәпкә алу һәм “Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы хакында” 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында федераль белешмәләр банкында беренчел исәпкә алу өчен бер үк вакытта Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган федераль башкарма хакимият органына җибәрү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына җибәрергә тиеш.

3. Опека һәм попечительлек органы әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр алган көннән алып бер ай дәвамында ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган бала турында документлаштырылган мәгълүматны ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар хакында республика белешмәләр банкында исәпкә алу, баланы Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнары гаиләсенә урнаштыруны оештыру һәм “Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында дәүләт белешмәләр банкы хакында” 2001 елның 16 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар турында федераль белешмәләр банкында исәпкә алу өчен бер үк вакытта тиешле федераль башкарма хакимият органына җибәрү өчен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органына җибәрергә тиеш.

4. Ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар булган мәгариф оешмаларының, медицина оешмаларының, социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның яисә шундый оешмаларның җитәкчеләре баланың гаиләгә тәрбиягә тапшырыла алуы турында үзләренә мәгълүм булган көннән алып өч эш көне дәвамында бу хакта аны гаиләгә тәрбиягә урнаштыруны оештыру өчен тиешле оешма урнашкан урындагы опека һәм попечительлек органына хәбәр итәргә тиеш.

5. Опека һәм попечительлек органы әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән белешмәләр кергән көннән алып бер ай эчендә баланы урнаштыруны тәэмин итә.

6. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мәгариф өлкәсендә дәүләт идарәсен гамәлгә ашыручы органы әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән алып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнары гаиләсенә урнаштыруны оештыра, ә мондый мөмкинлек булмаганда, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән мәгълүмат кергән көннән алып бер ай үткәннән соң Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган федераль башкарма хакимият органы баланы Россия Федерациясе территориясендә Россия Федерациясе гражданнары гаиләсенә тәрбиягә урнаштыруда ярдәм итә.

7. Әлеге статьяның 4 – 6 өлешләрендә каралган бурычларны үтәмәгән өчен, белә торып дөрес булмаган белешмәләр биргән өчен, баланы гаиләгә тәрбиягә тапшырудан яшереп калдыруга юнәлдерелгән башка гамәлләр өчен әлеге статьяның 4 – 6 өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларның җитәкчеләре һәм органнарның вазыйфаи затлары законда билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартылалар.”;

2) 114 статьяның 1 өлешендә “4 – 6 өлешләрендә” сүзләрен “3 – 6 өлешләрендә” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 30 июне
№ 56-ТРЗ